**СОВЕТ НИКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422627 с. Никольское,
ул. Центральная, д.35
тел: 4-31-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422627 Никольский авылы,
Әзәк урамы, 35 нчы йорт,
тел: 4-31-44

---

2020елның 15ноябре 57 номер

## КАРАР

### Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Никольский торак пункты гражданнары җыенының карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Никольский торак пункты гражданнары җыены карар кабул итте**:**

1. Лаеш муниципаль районының Никольский торак пункты _ Никольский авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда үзара салым чараларын 500 сум күләмендә кертергә, моңа балачактан көндезге формада белем алучы студентлар һәм инвалидлар керми.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә.:

- **Никольский авылындагы зиратны төзекләндерү**

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru.веб-адрес буенча, интернет-телекоммуникация челтәрендәге Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча, Лаеш шәһәре һәм Никольский авылының махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _________________ Э.Х.Алеев

Никольский авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе _________________ Э.Х.Алеев